ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино ,
Арский муниципальный район, 422013

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

« 24 » декабрь 2021ел . № 40

**«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 08 ноябрь 2021 ел № 1, 08 ноябрь 2021 ел № 2, 09 ноябрь 2021ел №3 җыеннарда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 33 номерлы Кәче авыл җирлеге Советы карары нигезендә Кәче авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урамы, 200 йорт; ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты; ТР, Арча районы, Якты-Көн авылы, Якты урамы, 30а йорты.

3. «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Кәче авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 41 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге
башлыгы урынбасары

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Гарифҗанов А.С.

Кәче авыл җирлеге Башкарма
комитетының
24 декабрь 2021 ел, №40
карарына 1 нче кушымта

**«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 09 февраленә кадәр «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) көндезге формада укучы студентлар,

б) 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннарда билгеләнгән суммадан 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, « Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кәче авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24 декабрь 2021ел, № 40
карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
« Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и._______________________________________________
Адресы:___________________________________________________________
_____________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
__________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № ___________________________________
Счетны алучы. № _______________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _________________ОКТМО_________________
Түләү билгеләнеше- гражданнарның шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары

бер тапкыр түләнә торган түләү кертергә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М. у.
- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Түләүченең ф. и. а.и.___________________________________________
Адресы: ___________________________________________________
______________сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган үзара салымны «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына кертү турында ___ номерлы хәбәрне (хәбәрнамә) алдым:

«___» __________ 20__ ел ____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзек корешок тутырыла һәм ______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*